КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026, 2 апрель г.Казань № 338

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт торак күзәтчелеге турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 сентябрь, 759 нчы, 2013 ел, 20 апрель, 272 нче, 2013 ел, 3 июль, 468 нче, 2013 ел, 18 декабрь, 1002 нче, 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче, 2016 ел, 16 сентябрь, 647 нче, 2017 ел, 2 август, 539 нчы, 2018 ел, 11 гыйнвар, 2 нче, 2018 ел, 9 апрель, 218 нче, 2018 ел, 24 август, 706 нчы, 2018 ел, 4 октябрь, 904 нче, 2018 ел, 23 ноябрь, 1041 нче, 2019 ел, 22 гыйнвар, 31 нче, 2019 ел, 21 июнь, 506 нчы, 2019 ел, 12 июль, 569 нчы, 2020 ел, 12 март, 185 нче, 2020 ел, 18 апрель, 305 нче, 2020 ел, 28 август, 750 нче, 2020 ел, 11 сентябрь, 824 нче, 2022 ел, 13 август, 809 нчы, 2023 ел, 4 февраль, 104 нче, 2023 ел, 7 июль, 795 нче, 2023 ел, 1 август, 916 нчы, 2023 ел, 16 декабрь, 1629 нчы, 2025 ел, 21 июль, 536 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.5 пунктта:

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

бишенче абзацта «(лицензия комиссиясе карары нигезендә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.11 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, ведомство бүләкләрен (аерымлык билгеләрен, бүләкләүнең башка төрләрен) гамәлгә куя һәм алар белән Инспекция хезмәткәрләрен, шулай ук билгеләнгән өлкәдә эшчәнлек алып баручы һәм Инспекциягә йөкләнгән бурычларны хәл итүдә ярдәм күрсәтүче башка затларны бүләкли.».

2. Бу карарның 1 пунктының икенче - дүртенче абзацлары 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин